# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге Кызыл Уракчы авыл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**2023 елның 9 октябреннән** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 9 октябрендә 13 сәгатьтә узган гражданнар җыеныныщ нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде, түбәндәге сорау буенча «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Зирекле авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге территориясендәге Кызыл Уракчы авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан,көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

- җирлек эчендәге юлларны карап тоту;
- җирлек эчендәге юлларны ремонтлау;
- торак пунктларда урам утларын карап тоту;
- су челтәрләрен карап тоту;
- торак пунктны төзекләндерү;

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Зирекле авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт бирергә.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 65 кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 835 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

«ЯКЛЫЙМ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 35 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Алексеевск муниципаль районы Зирекле авыл җирлегендәге Кызыл Уракчы авыл торак пунктында гражданнар җыены булып узды дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга: «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Зирекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Кызыл Уракчы авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

-җирлек эчендәге юлларны карап тоту;

- җирлек эчендәге юлларны ремонтлау;

- торак пунктларда урам утларын карап тоту;

- су челтәрләрен карап тоту;

- торак пунктны төзекләндерү;

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Зирекле авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт бирергә.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен , кабул ителгән көннән 10 көн эчендә Зирекле авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә , Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге башлыгы ____________ Зиннәтуллин А.Р.
( имза ) (имзаны расшифрлау)

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ЕРЫКЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
р05-1112413
СОВЕТ ЕРЫКЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ